КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 май г.Казань № 357

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әгерҗе», «Биләр», «Сорнар» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыклары турындагы нигезләмәләрне раслау турында» 2004 ел, 17 ноябрь, 494 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 декабрь, 780 нче; 2009 ел, 13 май, 302 нче; 2009 ел, 8 июль, 465 нче; 2009 ел, 12 август, 550 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 737 нче; 2018 ел, 21 май, 382 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 27 март, 226 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче; 2022 ел, 22 февраль, 152 нче; 2023 ел, 13 ноябрь, 1472 нче; 2024 ел, 18 март, 155 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Әгерҗе» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (kararга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Биләр» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Сорнар» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче;

2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 953 нче; 2022 ел, 26 октябрь, 1144 нче; 2022 ел, 2 декабрь, 1277 нче; 2023 ел, 18 февраль, 152 нче; 2023 ел, 24 март, 344 нче; 2023 ел, 13 ноябрь, 1472 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1756 нчы; 2024 ел, 26 февраль, 97 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтада:

«Әгерҗе [3]» бүлегендә «30,9 мең гектар» сүзләрен «30,089 мең гектар» сүзләренә алмаштырырга;

«Биләр [12]» бүлегендә «12,9 мең гектар» сүзләрен «13,059 мең гектар» сүзләренә алмаштырырга;

«Сорнар [35]» бүлегендә «13,496 мең гектар» сүзләрен «12,273 мең гектар» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 ел, 18 март, 155 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 20 май, 340 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктта «4 пунктындагы бишенче, тугызынчы һәм унөченче абзацларыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 29 гыйнвар, 41 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 май, 357 нче
карары редакциясендә)

«Әгерҗе» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать
зоология (аучылык) тыюлыгы турында
нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Әгерҗе» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы (алга таба – тыюлык) Татарстан Республикасы территориясендә Кама алды зонасында урман тавыгы һәм елга кондызы популяцияләрен торгызу һәм саклау, шулай ук кирәкле биотехник чаралар комплексын үткәрү юлы белән аларны торгызу өчен уңай шартлар тудыру максаты белән оештырылган төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территориясе булып тора.

Тыюлык Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территория-сендә, җир кишәрлекләрен аның чигенә керүче файдаланучылардан, хуҗалардан һәм милекчеләрдән алмыйча, Татарстан АССР Министрлар Советының «Әгерҗе дәүләт тыюлыгын оештыру һәм Кайбыч, Кама-Ык, Столбище, Ширәмәт, Шумбут һәм Мишә дәүләт тыюлыкларының гамәлдә булу срогын озайту турында» 1984 елның 20 декабрендәге 686 номерлы карары нигезендә оештырыла, аның гомуми мәйданы 31,089 мең гектар тәшкил итә.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Тыюлыкның территорияләре чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагында.

Дәүләт комитетының урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 нчы йорт.

1.4. Тыюлык чикләре һәм аның махсус саклау режимы территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы чараларын башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

II. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары

2.1. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары:

биологик төрлелекне саклап калуны тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

## III. Тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча Дәүләт комитетының функцияләре

3.1. Дәүләт комитеты тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, яңадан үрчетү белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларны файдалану өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару;

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле күзәтчелеге (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) саклавын тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген кертеп).

## IV. Тыюлыкны махсус саклау режимы

4.1. Тыюлык территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

промысел аучылыгы;

тояклы хайваннарга һәвәскәрләр һәм спорт аулавыннан тыш, һәвәскәрләр һәм спорт аулавы;

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (фәнни максатларда, тояклы хайваннарга һәвәскәрләр һәм спорт аулавы максатларында файдаланудан, хайваннар дөньясы объектлары санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

агачларны, куакларны кисү һәм (яисә) үсемлекләр капламын бозу (урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын уздыру очракларыннан тыш); урманнарны саклау, яклау һәм яңадан җитештерү; табигать комплексларын һәм тыюлык объектларын саклау һәм торгызу максатларында; гражданнар куркынычсызлыгын тәэмин итү, линия объектларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, шул исәптән аларны саклау зоналары киңлеген саклау буенча, линия объектларына техник хезмәт күрсәтү кысаларында реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау буенча һәм яңа линия объектларын төзегәндә;

торак пунктлар чикләрендә мондый төзелештән тыш, биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очракларда;

торак пунктлар чикләреннән чыгып, автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агызыла торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

әгәр тыюблыкның табигать комплексларына зыян китерсәләр, гидрологик режимны үзгәртү, су ресурсларын эксплуатацияләү;

тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карларны бер урынга өю (торак пунктлары чикләрендә мондый өюләрдән тыш);

учаклар кабызу, корыган яфракларны һәм үләннәрне яндыру;

торак пунктлар чикләреннән читтә, торак пунктлар чикләрендә туфрак катламын бозу, җир эшләре башкару (авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә авыл хуҗалыгы эшләрен башкарудан, урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын башкарудан, фәнни тикшеренүләр уздырудан тыш, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзүгә бәйле очраклардан тыш);

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

гомуми файдаланудагы юллардан читтә механик транспорт чаралары, юллары булмаган урыннарда йөри торган мототранспорт чаралары һәм махсус техника йөрү һәм аларны вакытлыча куеп тору (мондый чаралар һәм махсус техника йөрүдән һәм аларны вакытлыча куеп торудан тыш):

авыл хуҗалыгы эшләрен уздыру чорында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең;

махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына һәм инженерлык-техник коммуникацияләргә хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, фәнни тикшеренүләрне үткәрү, шулай ук аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

шартнамәләр нигезендә тыюлык территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан асфальтланган керү юллары булмаган торак пунктларга керү;

тыюлыктагы табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, тыюлык территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының сакланыла торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.2. Тыюлык территориясендә, Дәүләт комитеты белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

тыюлык булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; яңа инженерлык һәм техник коммуникацияләр, линия объектлары төзү, элек төзелгәннәрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау (тыюлыкның чикләреннән чыгып аларны урнаштыру вариантлары булмаган очракта); элегрәк төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын һәм инженерлык-техник коммуникацияләрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

бу пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;

җир кишәрлекләрен һәм су объектларын экологик реабилитацияләү, җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнү, шулай ук җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклылыгын геологик өйрәнү һәм бәяләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

биотөрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларны өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү, шулай ук археологик мирас объектларын ачыклау, өйрәнү һәм саклау максаты белән археологик кыр эшләрен башкару;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

төбәк геологиясен өйрәнү;

печән чабу, мал-туар көтү;

умарта оялары һәм умарталыклар урнаштыру.

4.3. Тыюлык территориясендә хуҗалык һәм башка эшчәнлек әлеге Нигезләмә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## V. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

5.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре, әгәр алар әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

үсемлекчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.1*);

бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.2*);

яшелчәчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.3*);

тонусны күтәрә торган, дару, чәчәк культураларын үстерү (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.4*);

бакчачылык (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.5*);

терлекчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.8*);

кошчылык (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.10*);

умартачылык (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.12*);

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (1.16*);

питомниклар (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.17*);

печән чабу (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.19*);

---

*Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.12*);

индивидуаль торак төзелеше өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.1*);

шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып бару өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.2*);

торак төзелешенә хезмәт күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (2.7*);

коммуналь хезмәтләр күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.1.1*);

коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары (торак пунктлар чикләрендә) (3.1.2*);

социаль хезмәт күрсәтү йортлары (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.1*);

халыкка социаль ярдәм күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.2*);

элемтә хезмәтләре күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.3*);

тулай торак (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.4*);

көнкүреш хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.3*);

амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.4.1*);

стационар медицина хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.4.2*);

мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем (торак пунктлар чикләрендә) (3.5.1*);

урта һәм югары һөнәри белем бирү (торак пунктлар чикләрендә) (3.5.2*);

мәдәният-ял итү эшчәнлеге объектлары (торак пунктлар чикләрендә) (3.6.1*);

мәдәният һәм ял парклары (торак пунктлар чикләрендә) (3.6.2*);

дини йолаларны гамәлгә ашыру (торак пунктлар чикләрендә) (3.7.1*);

дини идарә һәм мәгариф (торак пунктлар чикләрендә) (3.7.2*);

дәүләт идарәсе (торак пунктлар чикләрендә) (3.8.1*);

гидрометеорология өлкәсендә һәм аның белән чиктәш өлкәләрдә эшчәнлекне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.1*);

фәнни тикшеренүләр үткәрү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.2*);

фәнни сынаулар үткәрү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.3*);

амбулатор ветеринария хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.10.1*);

хайваннар өчен приютлар (торак пунктлар чикләрендә) (3.10.2*);

сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары) (торак пунктлар чикләрендә) (4.2*);

базарлар (торак пунктлар чикләрендә) (4.3*);

кибетләр (торак пунктлар чикләрендә) (4.4*);

банк һәм иминият эшчәнлеге (торак пунктлар чикләрендә) (4.5*);

җәмәгать туклануы (торак пунктлар чикләрендә) (4.6*);

кунакханә хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (4.7*);

хезмәт урынындагы гаражлар (торак пунктлар чикләрендә) (4.9*);

транспорт чараларына ягулык салу (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.1*);

юлда ял итүне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.2*);

автомобиль юу урыннары (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.3*);

автомобильләрне ремонтлау (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.4*);

күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге (торак пунктлар чикләрендә) (4.10*);

спорт-тамаша чараларын тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.1*);

биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.2*);

спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.3*);

спорт белән шөгыльләнү өчен җиһазландырылган мәйданчыклар (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.4*);

табигатьне танып белү туризмы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.2*);

туристлык хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (5.2.1*);

җир асты байлыкларыннан файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (6.1*);

азык-төлек сәнәгате (торак пунктлар чикләрендә) (6.4*);

элемтә (торак пунктлар чикләрендә) (6.8*);

складлар (торак пунктлар чикләрендә) (6.9*);

склад мәйданчыклары (торак пунктлар чикләрендә) (6.9.1*);

гомуми файдаланудагы транспортны куеп тору урыннары (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.2.3*);

табигать территорияләрен саклау (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.3*);

урман ресурсларын әзерләү (10.3*);

резерв урманнары (Дәүләт комитеты белән килештереп) (10.4*);

су объектларыннан гомуми файдалану (11.1*);

урам-юл челтәре (торак пунктлар чикләрендә) (12.0.1*);

яшелчәчелек алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (13.1*);

бакчачылыкны алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (13.2*).

## VI. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

6.1. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик биеклеге – ике кат;

җир кишәрлеге чикләрендә йорт салу проценты – иң күбе 50 процент.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 29 гыйнвар, 41 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 май, 357 нче
карары редакциясендә)

# «Биләр» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Биләр» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы (алга таба – тыюлык) Татарстан Республикасы территориясендә Кама артының экология-география зонасында ау объектларына кертеп каралган хайваннар дөньясы объектлары популяцияләрен торгызу һәм саклау, шулай ук кирәкле биотехник чаралар комплексын үткәрү юлы белән аларны торгызу өчен уңай шартлар тудыру максаты белән оештырылган төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территориясе булып тора.

Тыюлык Татарстан Республикасы Аксубай, Алексеевск һәм Нурлат муниципаль районнары территориясендә, җир кишәрлекләрен аның чигенә керүче файдаланучылардан, хуҗалардан һәм милекчеләрдән алмыйча, Татарстан АССР Министрлар Советының 1967 елның 16 октябрендәге 6-927 номерлы боерыгы нигезендә оештырыла, аның гомуми мәйданы 13,059 мең гектар тәшкил итә.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Тыюлыкның территорияләре чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагында.

Дәүләт комитетының урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 нчы йорт.

1.4. Тыюлык чикләре һәм аның махсус саклау режимы территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы чараларын башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

## II. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары

2.1. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары:
биологик төрлелекне саклап калуны тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

III. Тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча Дәүләт комитетының функцияләре

3.1. Дәүләт комитеты тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, яңадан үрчетү белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларны файдалану өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару;

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле күзәтчелеге (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) саклавын тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген кертеп).

IV. Тыюлыкны махсус саклау режимы

4.1. Тыюлык территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

промысел аучылыгы;

тояклы хайваннарга һәвәскәрләр һәм спорт аулавыннан тыш, һәвәскәрләр һәм спорт аулавы;

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (фәнни максатларда, тояклы хайваннарга һәвәскәрләр һәм спорт аулавы максатларында файдаланудан, хайваннар дөньясы объектлары санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

агачларны, куакларны кисү һәм (яисә) үсемлекләр капламын бозу (урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын уздыру очракларыннан тыш); урманнарны саклау, яклау һәм яңадан җитештерү; табигать комплексларын һәм тыюлык объектларын саклау һәм торгызу максатларында; гражданнар куркынычсызлыгын тәэмин итү, линия объектларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, шул исәптән аларны саклау зоналары киңлеген саклау буенча, линия объектларына техник хезмәт күрсәтү кысаларында реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау буенча һәм яңа линия объектларын төзегәндә;

торак пунктлар чикләрендә мондый төзелештән тыш, биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очракларда;

торак пунктлар чикләреннән чыгып, автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агызыла торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

әгәр тыюблыкның табигать комплексларына зыян китерсәләр, гидрологик режимны үзгәртү, су ресурсларын эксплуатацияләү;

тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карларны бер урынга өю (торак пунктлары чикләрендә мондый өюләрдән тыш);

учаклар кабызу, корыган яфракларны һәм үләннәрне яндыру;

торак пунктлар чикләреннән читтә, торак пунктлар чикләрендә туфрак катламын бозу, җир эшләре башкару (авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә авыл хуҗалыгы эшләрен башкарудан, урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын башкарудан, фәнни тикшеренүләр уздырудан тыш, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзүгә бәйле очраклардан тыш);

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

гомуми файдаланудагы юллардан читтә механик транспорт чаралары, юллары булмаган урыннарда йөри торган мототранспорт чаралары һәм махсус техника йөрү һәм аларны вакытлыча куеп тору (мондый чаралар һәм махсус техника йөрүдән һәм аларны вакытлыча куеп торудан тыш):

авыл хуҗалыгы эшләрен уздыру чорында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең;

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына һәм инженерлык-техник коммуникацияләргә хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, фәнни тикшеренүләрне үткәрү, шулай ук аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

шартнамәләр нигезендә тыюлык территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан асфальтланган керү юллары булмаган торак пунктларга керү;

тыюлыктагы табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, тыюлык территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының сакланыла торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.2. Тыюлык территориясендә, Дәүләт комитеты белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

тыюлык булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; яңа инженерлык һәм техник коммуникацияләр, линия объектлары төзү, элек төзелгәннәрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау (тыюлыкның чикләреннән чыгып аларны урнаштыру вариантлары булмаган очракта); элегрәк төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын һәм инженерлык-техник коммуникацияләрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

бу пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;

җир кишәрлекләрен һәм су объектларын экологик реабилитацияләү, җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнү, шулай ук җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклылыгын геологик өйрәнү һәм бәяләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

биотөрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларны өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү, шулай ук археологик мирас объектларын ачыклау, өйрәнү һәм саклау максаты белән археологик кыр эшләрен башкару;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

төбәк геологиясен өйрәнү;

печән чабу, мал-туар көтү;

умарта оялары һәм умарталыклар урнаштыру.

4.3. Тыюлык территориясендә хуҗалык һәм башка эшчәнлек әлеге Нигезләмә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## V. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

5.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре, әгәр алар әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

үсемлекчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.1*);

бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.2*);

яшелчәчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.3*);

тонусны күтәрә торган, дару, чәчәк культураларын үстерү (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.4*);

бакчачылык (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.5*);

терлекчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.8*);

кошчылык (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.10*);

умартачылык (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.12*);

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (1.16*);

питомниклар (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.17*);

печән чабу (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.19*);

---

*Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.12*);
индивидуаль торак төзелеше өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.1*);
шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып бару өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.2*);
торак төзелешенә хезмәт күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (2.7*);
коммуналь хезмәтләр күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.1.1*);
коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары (торак пунктлар чикләрендә) (3.1.2*);
социаль хезмәт күрсәтү йортлары (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.1*);
халыкка социаль ярдәм күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.2*);
элемтә хезмәтләре күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.3*);
тулай торак (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.4*);
көнкүреш хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.3*);
амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.4.1*);
стационар медицина хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.4.2*);
мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем (торак пунктлар чикләрендә) (3.5.1*);
урта һәм югары һөнәри белем бирү (торак пунктлар чикләрендә) (3.5.2*);
мәдәният-ял итү эшчәнлеге объектлары (торак пунктлар чикләрендә) (3.6.1*);
мәдәният һәм ял парклары (торак пунктлар чикләрендә) (3.6.2*);
дини йолаларны гамәлгә ашыру (торак пунктлар чикләрендә) (3.7.1*);
дини идарә һәм мәгариф (торак пунктлар чикләрендә) (3.7.2*);
дәүләт идарәсе (торак пунктлар чикләрендә) (3.8.1*);
гидрометеорология өлкәсендә һәм аның белән чиктәш өлкәләрдә эшчәнлекне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.1*);
фәнни тикшеренүләр үткәрү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.2*);
фәнни сынаулар үткәрү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.3*);
амбулатор ветеринария хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.10.1*);
хайваннар өчен приютлар (торак пунктлар чикләрендә) (3.10.2*);
сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары) (торак пунктлар чикләрендә) (4.2*);
базарлар (торак пунктлар чикләрендә) (4.3*);
кибетләр (торак пунктлар чикләрендә) (4.4*);
банк һәм иминият эшчәнлеге (торак пунктлар чикләрендә) (4.5*);
җәмәгать туклануы (торак пунктлар чикләрендә) (4.6*);
кунакханә хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (4.7*);
хезмәт урынындагы гаражлар (торак пунктлар чикләрендә) (4.9*);
транспорт чараларына ягулык салу (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.1*);
юлда ял итүне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.2*);
автомобиль юу урыннары (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.3*);
автомобильләрне ремонтлау (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.4*);
күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге (торак пунктлар чикләрендә) (4.10*);
спорт-тамаша чараларын тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.1*);
биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.2*);

спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.3*);

спорт белән шөгыльләнү өчен җиһазландырылган мәйданчыклар (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.4*);

табигатьне танып белү туризмы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.2*);

туристлык хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (5.2.1*);

җир асты байлыкларыннан файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (6.1*);

азык-төлек сәнәгате (торак пунктлар чикләрендә) (6.4*);

элемтә (торак пунктлар чикләрендә) (6.8*);

складлар (торак пунктлар чикләрендә) (6.9*);

склад мәйданчыклары (торак пунктлар чикләрендә) (6.9.1*);

гомуми файдаланудагы транспортны куеп тору урыннары (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.2.3*);

табигать территорияләрен саклау (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.3*);

урман ресурсларын әзерләү (10.3*);

резерв урманнары (Дәүләт комитеты белән килештереп) (10.4*);

су объектларыннан гомуми файдалану (11.1*);

урам-юл челтәре (торак пунктлар чикләрендә) (12.0.1*);

яшелчәчелек алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (13.1*);

бакчачылыкны алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (13.2*).

## VI. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

6.1. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик биеклеге – ике кат;

җир кишәрлеге чикләрендә йорт салу проценты – иң күбе 50 процент.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 29 гыйнвар, 41 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 май, 357 нче
карары редакциясендә)

## «Сорнар» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Сорнар» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы (алга таба – тыюлык) Татарстан Республикасы территориясендә Кама алдының экология-география зонасында ау объектларына кертеп каралган хайваннар дөньясы объектлары, ягъни елга кондызы, тиен, кыр тавыгы популяцияләрен һәм аларның яшәү мохитен торгызу һәм саклау, шулай ук кирәкле биотехник чаралар комплексын үткәрү юлы белән аларны торгызу өчен уңай шартлар тудыру максаты белән оештырылган төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территориясе булып тора.

Тыюлык Татарстан Республикасы Арча һәм Балтач муниципаль районнары территориясендә, җир кишәрлекләрен аның чигенә керүче файдаланучылардан, хуҗалардан һәм милекчеләрдән алмыйча, Татарстан АССР Министрлар Советының 1965 елның 21 сентябрендәге 495 номерлы карары нигезендә оештырыла, аның гомуми мәйданы 12,273 мең гектар тәшкил итә.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Тыюлыкның территорияләре чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагында.

Дәүләт комитетының урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 нчы йорт.

1.4. Тыюлык чикләре һәм аның махсус саклау режимы территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы чараларын башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

### II. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары

2.1. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Дәүләт комитетының төп бурычлары:
биологик төрлелекне саклап калуны тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

III. Тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча Дәүләт комитетының функцияләре

3.1. Дәүләт комитеты тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, яңадан үрчетү белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларны файдалану өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару;

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле күзәтчелеге (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) саклавын тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген кертеп).

IV. Тыюлыкны махсус саклау режимы

4.1. Тыюлык территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

промысел аучылыгы;

тояклы хайваннарга һәвәскәрләр һәм спорт аулавыннан тыш, һәвәскәрләр һәм спорт аулавы;

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (фәнни максатларда, тояклы хайваннарга һәвәскәрләр һәм спорт аулавы максатларында файдаланудан, хайваннар дөньясы объектлары санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

агачларны, куакларны кисү һәм (яисә) үсемлекләр капламын бозу (урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын уздыру очракларыннан тыш); урманнарны саклау, яклау һәм яңадан җитештерү; табигать комплексларын һәм тыюлык объектларын саклау һәм торгызу максатларында; гражданнар куркынычсызлыгын тәэмин итү, линия объектларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, шул исәптән аларны саклау зоналары киңлеген саклау буенча, линия объектларына техник хезмәт күрсәтү кысаларында реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау буенча һәм яңа линия объектларын төзегәндә;

торак пунктлар чикләрендә мондый төзелештән тыш, биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очракларда;

торак пунктлар чикләреннән чыгып, автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агызыла торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

әгәр тыюблыкның табигать комплексларына зыян китерсәләр, гидрологик режимны үзгәртү, су ресурсларын эксплуатацияләү;

тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карларны бер урынга өю (торак пунктлары чикләрендә мондый өюләрдән тыш);

учаклар кабызу, корыган яфракларны һәм үләннәрне яндыру;

торак пунктлар чикләреннән читтә, торак пунктлар чикләрендә туфрак катламын бозу, җир эшләре башкару (авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә авыл хуҗалыгы эшләрен башкарудан, урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын башкарудан, фәнни тикшеренүләр уздырудан тыш, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзүгә бәйле очраклардан тыш);

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

гомуми файдаланудагы юллардан читтә механик транспорт чаралары, юллары булмаган урыннарда йөри торган мототранспорт чаралары һәм махсус техника йөрү һәм аларны вакытлыча куеп тору (мондый чаралар һәм махсус техника йөрүдән һәм аларны вакытлыча куеп торудан тыш):

авыл хуҗалыгы эшләрен уздыру чорында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең;

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына һәм инженерлык-техник коммуникацияләргә хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, фәнни тикшеренүләрне үткәрү, шулай ук аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

шартнамәләр нигезендә тыюлык территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан асфальтланган керү юллары булмаган торак пунктларга керү;

тыюлыктагы табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, тыюлык территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.2. Тыюлык территориясендә, Дәүләт комитеты белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

тыюлык булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; яңа инженерлык һәм техник коммуникацияләр, линия объектлары төзү, элек төзелгәннәрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау (тыюлыкның чикләреннән чыгып аларны урнаштыру вариантлары булмаган очракта); элегрәк төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын һәм инженерлык-техник коммуникацияләрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

бу пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;

җир кишәрлекләрен һәм су объектларын экологик реабилитацияләү, җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнү, шулай ук җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклылыгын геологик өйрәнү һәм бәяләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

биотөрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларны өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү, шулай ук археологик мирас объектларын ачыклау, өйрәнү һәм саклау максаты белән археологик кыр эшләрен башкару;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

төбәк геологиясен өйрәнү;

печән чабу, мал-туар көтү;

умарта оялары һәм умарталыклар урнаштыру.

4.3. Тыюлык территориясендә хуҗалык һәм башка эшчәнлек әлеге Нигезләмә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы

турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## V. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

5.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре, әгәр алар әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

үсемлекчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.1*);

бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.2*);

яшелчәчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.3*);

тонусны күтәрә торган, дару, чәчәк культураларын үстерү (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.4*);

бакчачылык (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.5*);

терлекчелек (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.8*);

кошчылык (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.10*);

умартачылык (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.12*);

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (1.16*);

питомниклар (торак пунктлар чикләрендә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен бирелгән җирләрдә) (1.17*);

печән чабу (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.19*);

авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.20*);

индивидуаль торак төзелеше өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.1*);

шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып бару өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.2*);

---

*Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

торак төзелешенә хезмәт күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (2.7*);
коммуналь хезмәтләр күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.1.1*);
коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары (торак пунктлар чикләрендә) (3.1.2*);
социаль хезмәт күрсәтү йортлары (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.1*);
халыкка социаль ярдәм күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.2*);
элемтә хезмәтләре күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.3*);
тулай торак (торак пунктлар чикләрендә) (3.2.4*);
көнкүреш хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.3*);
амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.4.1*);
стационар медицина хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.4.2*);
мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем (торак пунктлар чикләрендә) (3.5.1*);
урта һәм югары һөнәри белем бирү (торак пунктлар чикләрендә) (3.5.2*);
мәдәният-ял итү эшчәнлеге объектлары (торак пунктлар чикләрендә) (3.6.1*);
мәдәният һәм ял парклары (торак пунктлар чикләрендә) (3.6.2*);
дини йолаларны гамәлгә ашыру (торак пунктлар чикләрендә) (3.7.1*);
дини идарә һәм мәгариф (торак пунктлар чикләрендә) (3.7.2*);
дәүләт идарәсе (торак пунктлар чикләрендә) (3.8.1*);
гидрометеорология өлкәсендә һәм аның белән чиктәш өлкәләрдә эшчәнлекне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.1*);
фәнни тикшеренүләр үткәрү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.2*);
фәнни сынаулар үткәрү (торак пунктлар чикләрендә) (3.9.3*);
амбулатор ветеринария хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (3.10.1*);
хайваннар өчен приютлар (торак пунктлар чикләрендә) (3.10.2*);
сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары) (торак пунктлар чикләрендә) (4.2*);
базарлар (торак пунктлар чикләрендә) (4.3*);
кибетләр (торак пунктлар чикләрендә) (4.4*);
банк һәм иминият эшчәнлеге (торак пунктлар чикләрендә) (4.5*);
җәмәгать туклануы (торак пунктлар чикләрендә) (4.6*);
кунакханә хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (4.7*);
хезмәт урыныңдагы гаражлар (торак пунктлар чикләрендә) (4.9*);
транспорт чараларына ягулык салу (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.1*);
юлда ял итүне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.2*);
автомобиль юу урыннары (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.3*);
автомобильләрне ремонтлау (торак пунктлар чикләрендә) (4.9.1.4*);
күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге (торак пунктлар чикләрендә) (4.10*);
спорт-тамаша чараларын тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.1*);
биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.2*);
спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.3*);

спорт белән шөгыльләнү өчен җиһазландырылган мәйданчыклар (торак пунктлар чикләрендә) (5.1.4*);

табигатьне танып белү туризмы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.2*);

туристлык хезмәте күрсәтү (торак пунктлар чикләрендә) (5.2.1*);

җир асты байлыкларыннан файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (6.1*);

азык-төлек сәнәгате (торак пунктлар чикләрендә) (6.4*);

элемтә (торак пунктлар чикләрендә) (6.8*);

складлар (торак пунктлар чикләрендә) (6.9*);

склад мәйданчыклары (торак пунктлар чикләрендә) (6.9.1*);

гомуми файдаланудагы транспортны куеп тору урыннары (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.2.3*);

табигать территорияләрен саклау (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.3*);

урман ресурсларын әзерләү (10.3*);

резерв урманнары (Дәүләт комитеты белән килештереп) (10.4*);

су объектларыннан гомуми файдалану (11.1*);

урам-юл челтәре (торак пунктлар чикләрендә) (12.0.1*);

яшелчәчелек алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (13.1*);

бакчачылыкны алып бару (торак пунктлар чикләрендә) (13.2*).

## VI. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

6.1. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик биеклеге – ике кат;

җир кишәрлеге чикләрендә йорт салу проценты – иң күбе 50 процент.

---